Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Кәвәл авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге
Кәвәл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

25 октябрь, 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлегенең Кәвәл торак пунктында 2024 елның 25 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 174 (йөз җитмеш дүрт).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 89 (туксан биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 95 (туксан биш).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2025 елда Кәвәл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларны һәм мәктәп укучыларын, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (бистә эчендәге юлларны ремонтлау)» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кәвәл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Кәвәл авыл җирлеге башлыгы М.Х. Камалиев